ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.05.2020 п.г.т.Алексеевское № 166

**«Баланы (балаларны) матди карап торуга акчаларны опекунга яисә попечительгә, тәрбиягә бала алучы ата-аналарга билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында, шулай ук түләүле вазыйфаларын башкаручы опекуннарга яисә попечительләргә, тәрбиягә бала алучы ата-аналарга тиешле түләүне түләү турында» Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 13 ноябрендәге 588 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 маддәсендәге 6 өлешенә үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә

**карар кылам:**

1. «Баланы (балаларны) матди карап торуга акчаларны билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында, опекунга яисә попечительгә, тәрбиягә бала алучы ата-аналарга, шулай ук түләүле вазыйфаларын башкаручы опекуннарга яисә попечительләргә, тәрбиягә бала алучы ата-аналарга тиешле түләүне түләү турында» Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 13 ноябрендәге 588 номерлы карарында 2.5 пунктының 6 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.В. Симашевага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**